Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

Татарстан Республикасы

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авылы
җирлеге башкарма комитеты

А.Валеев урамы, 53нче йорт, Илбәк авылы,
Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» ноябрь 2018 ел №23

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Илбәк авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенең 25.11.2018 елгы бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Илбәк авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварындагы 76 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Илбәк муниципаль берәмлегенең" җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә керешергә (26.09.2014 елгы №99, 01.12.2016 елгы №40, 04.09.2017 елгы №58, 03.07.2018 елгы №95 номерлы карарлар редакциясендә).

1.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелгән үзгәрешләр белән 1, 25-30 статьяларны яраштыру.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина

Азнакай муниципаль районы Илбәк
авыл җирлеге башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта
26.11.2018 ел №23

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүнең якынча сроклары**

| N | «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр керү турында проектны әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2018 елның IV кварталы |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 1, 25-30 статьяларын Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелгән үзгәрешләр белән яраштыру<br>Җирле үзидарә органы территориясен планлаштыру буенча документлар әзерләү турында бүлек эшләү<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволарның кисәтүләренә шәрехләр әзерләү. | 2018 елның IV кварталы |
| 3.<br><br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башлыгына “Илбәк авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) Карар кабул итү өчен җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын авыл җирлеге Советына раслауга яисә кире кагуга һәм аны кабат эшләп бетерү датасын күрсәтеп, эшләп бетерергә җибәрү. | I квартал 2019 ел |